КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь г.Казань № 1251

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 октябрь, 901 нче; 2021 ел, 22 июль, 644 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1284 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктта:

2.4.1 пунктчада «Татарстан Республикасы министрлыкларының, ведомстволарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.2.5 пунктча үз көчен югалткан дип таныргa;

2.3.13 пунктчада:

беренче абзацта «B», «C», «D», «E» категорияләрендәге» сүзләрен «A», «B», «C», «D», «BE», «CE», «DE», «M» категорияләрендәге» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «B», «C», «D», «E» категорияләрендәге» сүзләрен «A», «B», «C», «D», «BE», «CE», «DE», «M» категорияләрендәге» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.22 пунктчада «транспорт предприятиеләрендә һәм оешмаларда» сүзләрен «транспорт оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.23 пунктчада «хакимият органнарыннан, министрлыклардан, ведомстволардан, контрольдә тотучы органнардан, предприятиеләрдән» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, контрольдә тотучы органнардан, оешмалардан» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.27 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.27. Учреждение эшчәнлеге өчен кирәкле сатып алуларны гамәлгә ашыру, дәүләт программаларын гамәлгә ашыру;»;

2.6 пунктта:

дүртенче, бишенче һәм уникенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

егерме җиденче абзацта «предприятиенең» сүзен «оешманың» сүзенә алмаштырырга;

утыз дүртенче абзацта «, сатып алуда катнашуга заявка әзерләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

утыз сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«эвакуатор ярдәмендә транспортлау һәм транспорт чараларын саклау хезмәтләрен күрсәтү;

түләүле парковка урыны бирү хезмәтләре күрсәтү;

транспорт чарасын арендага бирү;

металл ватыклары кабул итү пунктларына транспорт чараларын утильләштерүгә тапшыру.»;

5.2 пунктта:

18 пунктчада «башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктчада «башкарма хакимиятнең дәүләт органы» сүзләрен «дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктның өченче абзацында «учреждениеләрдә, оешмаларда һәм предприятиеләрдә» сүзләрен «оешмаларда» сүзенә алмаштырырга;

6.2 пунктта «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыра торган транспорт чаралары салган зыянны каплау турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясеннән авыр йөк һәм зур үлчәмле йөк ташый торган автотранспорт чаралары хуҗаларыннан яки алардан файдаланучылардан түләү алу турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 ел, 20 март, 158 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясеннән авыр йөк һәм зур үлчәмле йөк ташый торган автотранспорт чаралары хуҗаларыннан яки алардан файдаланучылардан түләү алу турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 ел, 17 июль, 372 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөк һәм зур үлчәмле йөк ташый торган автотранспорт чаралары хуҗаларыннан яки алардан файдаланучылардан юл йөрү өчен түләү алу турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 ел, 4 август, 359 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөк һәм зур үлчәмле йөк ташый торган автотранспорт чаралары хуҗаларыннан яки алардан файдаланучылардан юл йөрү өчен түләү алу турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөк һәм зур үлчәмле йөк ташучы автотранспорт чаралары салган зыянны компенсацияләү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 24 апрель, 146 нчы;

«Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөкләр ташый торган транспорт чаралары китерә торган зыянның күләмен билгеләү турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөкләр ташый торган транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 9 июнь, 383 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан үткән өчен авыр һәм зур габаритлы йөкләр ташучы автомобиль транспорты чаралары хуҗаларыннан яисә алардан файдаланучылардан түләү алу турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 16 май, 322 нче карарының үз көчен югалтуын тану һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк һәм муниципаль районара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташучы транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 551 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 25 июнь, 423 нче;

«Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт

чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь 699 нчы карарына үзгәреш кертү турында» 2011 ел, 16 март, 192 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү турында» 2015 ел, 20 июнь, 445 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь 699 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 15 декабрь, 1147 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 6 июль, 552 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәреш кертү турында» 2022 ел, 1 апрель, 307 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 ел, 2 август, 752 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле

транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәреш кертү турында» 2023 ел, 24 март, 331 нче.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацының гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карарның 2 пункты 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин